УДК 93/94+929

# «ФИДАКАРЬ ҺӘМ НЕЧКӘ КҮҢЕЛЛЕ ТАБИБӘ» РАБИГА АРАТ

***М.Р. Гайнанова***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*mgaynanova@gmail.com*

Мәкаләдә Рабига Аратның тормыш иптәше, танылган галим, тюрколог Рәшит Рәхмәти Аратка язылган хаты анализлана. Тәкъдим ителгән документта гаилә яңалыклары, Төркиядә яшәүче татарларның тормышы турында мәгълүматлар бирелә. Әлеге шәхси характердагы документ безгә чит илдәге татар мөһаҗирләренең көнкүрешен аңларга ярдәм итә. Рабига Аратның хатында көндәлек тормыш, гаилә һәм дуслар белән мөнәсәбәтләре турында мәгълүмат бирелә. Текстның лейтмотивы булып Рабига ханымның мөһаҗирлектәге һөнәри эшчәнлеге белән бәйле борчулары ята. Хаттан аңлашылганча, моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт: татар хатын-кызының Ауропада алган югары медицина белеменә һәм табиблек тәҗрибәсенә Төркиядә ихтыяҗ булмый. Хатта татар мөһаҗирләре тормышына бәйле кайбер биографик материаллар белән дә танышырга мөмкин. Шулай ук Төркиянең социаль тормышында татар хатын-кызының урыны, тормышы һәм эшчәнлеге яктыртыла.

Мәкаләнең максаты – чит илдә татарларның көндәлек тормышын чагылдырган, төрле проблемаларга, вакыйгаларга мөнәсәбәтен күрсәткән хатка анализ нәтиҗәсен тәкъдим итү.

Язмада Рабига Аратның язган хаты һәм хәзерге татар теленә тәрҗемәсе китерелә. Чыганакта хатын-кызның шәхси тормышы, карьерасы, татар зыялылары белән үзара мөнәсәбәте һәм төрле мәсьәләләргә карата кичерешләре, уңышсызлыкларны кабул итә белүе турында языла. Әлеге хат фәнни әйләнешкә беренче мәртәбә кертелә. Шулай итеп, Рәшит Рәхмәти Аратның гаиләсе турында моңарчы аз билгеле булган фактлар яктыртыла.

**Ачкыч сүзләр:** Рабига Арат, Төркия, шәхси архив, эпистоляр жанр, биография.

XX гасыр татар мөһаҗирләренең күренекле вәкилләре арасында үрнәк татар гаиләсе булып Аратлар санала. Төркиядә мәшһүр галим, профессор булып танылган, тюркология фәнендә тирән эз калдырган Рәшит Рәхмәти Аратның (1900–1964) һөнәри уңышларында хәләл җефете Рабига ханымның да роле зур. Ул иренең чын мәгънәсендә фикердәше, киңәшчесе һәм алыштыргысыз ярдәмчесе була.

Рабига Рәхмәти Арат (кыз фамилиясе Ибраһим) 1901 елда Пермь шәһәрендә татар сәүдәгәрләре гаиләсендә дөньяга килә. Рус гимназиясен тәмамлап, Томск университетының медицина бүлегенә укырга керә, тик совет хакимиятен кабул итмичә, 1919 елда башка татар яшьләре белән Харбинга китә (Çağatay, 1965: 180).

*© Гайнанова М.Р., 2024*

Биредә яшь кыз Рәшит Рәхмәти белән таныша һәм аның кәләше буларак, әти-әнисенең ризалыгы белән, 1922 елда Германиягә укырга китә. 1927 елда Берлин университетының медицина бүлеген тәмамлый һәм Рәхмәти белән гаилә кора. Кызлары Сөем (1931) белән Айсу (1935) туа (Arslan, 1974: 42).

Рабига ханым Берлинда авыруларны кабул итү бүлмәсен ача, табибә булып эшли. 1933 елда Рәшит Рәхмәти Арат Истанбул университетыннан эшкә чакыру алгач, яшь гаилә Төркиягә күченә. Истанбулда Рабига Арат «хастаханәләрдә, фабрикаларда, уку йортларында табибә булып эшли. [...] шул ук вакытта тормыш иптәше Рәшит бәйгә зур терәк була» (Arslan, 1974: 42).

2019 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан оештырылган фәнни экспедиция вакытында Әнкарадагы Төрек тарих җәмгыяте архивында Рабига Аратның иренә адресланган сигез хаты ачыкланды. Әлеге хатлар 1933–1935 елларга карыйлар һәм иске татар телендә гарәп шрифтында язылганнар. Текстларда шулай ук гарәп һәм төрек сүзләре дә очрый. Мәкаләдә бирелгән хатны хәзерге татар теленә күчергәндә, мөмкин кадәр авторның язма стилен һәм лексикасын сакларга тырыштык.

Мәкаләдә тәкъдим ителгән хат (TTK_Fi_2_6_6) Рәшит әфәндегә Берлинга языла. 1935–1936 елларда ул фәнни эш буенча Германиядә командировкада була. Барлык гаилә мәшәкатьләрен үз өстенә Рабига ханым ала. Хаттан күренгәнчә, ул Төркиядә яшәгән татар зыялылары белән якын элемтәдә була. Һәрдаим алар белән күрешеп, ярдәмләшеп тора. Татар җәмгыятендә булган барлык яңалыклар белән ирен һәрвакыт хәбәрдәр тота.

Төркия чорында Рабига ханымның табиблек эше җиңел генә бармый. Ул даими бер эшкә урнаша алмый, аңа татар зыялылары ярдәм итәргә тырышсалар да, төрле сәбәпләр аркасында эш табу уңышсызлыклар белән тәмамлана. Рабига Арат эчке кичерешләре, борчулары белән бары тик тормыш иптәше белән генә уртаклаша ала, шул ук вакытта борчыганы өчен аннан гафу дә үтенә.

Ислам дине һәм халыкның милли-мәдәни традицияләре, гореф-гадәтләре мохитендә тәрбияләнгән татар хатын-кызы өчен беренче урында, әлбәттә, гаилә тора. Нәтиҗәдә ул авыруларны кабул итүдән туктый һәм тормыш иптәше Рәшит Рәхмәти Аратка ныклы терәк, кызларына кадерле әни була, үзенең барлыгын гаиләсенә багышлый.

Рабига Арат 1974 елда бакыйлыкка күчә. Аның истәлегенә багышлап, «Kazan» журналында мәкалә басылып чыга. Автор аны «фидакарь һәм нечкә күңелле табибә» дип атый һәм җылы сүзләр белән искә ала: «Балаларга һәм олыларга ярдәмче булган, һәммәбезнең дәртенә, мәсьәләсенә чара тапкан, ярдәмен кызганмаган, игелекле, белемле ханымдыр. Ул эмиграциядә югары белем алып, табибә булган ике хатын-кызның берседер. Табибә Рабига ханым кебек мөһаҗирлектә авыр тормышта җитешкән, белем алган башка ханым докторлар юктыр. Без аны һәрвакыт хөрмәт белән искә алачакбыз» (Arslan, 1974: 42).

Замандашлары тарафыннан язылган әлеге сүзләр Рабига Аратның шәхесенә карата әйтелгән иң югары бәядер.

Рабига Аратның тормыш иптәше Р.Р. Аратка язган хаты (TTK_Fi_2_6_6)


DOKTOR
RABİA RAHMETİ ARAT
DİPLOMA No. 753/3170
CAĞALOĞLU, NURUOSMANİYE CADDESİ No. 30
(KAPALI FIRIN KARŞISINDA)
TELEFON: 21614

Istanbul, 20. VIII 1935


جمعه ایرته سی کون تیلیفون ایتکن دی. دیمک تاغی
دورت کوندن. تاغی اوزون دورت کونی بیلگو-
سزلک ایچینده اوتکاررگه کیره ک.
بلسه ک ایدی نه سیزه میم؟ بو کونگه دن، بو قدر توزدن
نی قدر توقیا تمی. بعضا دوقتر لقمه ده بونلری
واز کیچو درجه سینه جیتام. سینی مونری کوکلسز تویه-
یازوب بو بولومه عفو ایت، یازماسچی بولمیم، تیک بو کون
... اومر دن تاغی بیله سیزله توب قاتیم. دیمک
بو یولی ده بلکه منیم عائله لی بولووم نی سبب ایتوب
آلا الماملار.
بو عتاقی وقت کوکللی کنه اوتدی. کوزت دن استانبولغه
کیلودن یولده وقت کوکللی اوتدی. تاشلر کوب. کیچ
قاشقاندن دیکادن الله یار بوله تاشوب سویله شوب
قالیدم. صمیمی ... .
... کرگاندن سیارسینی اوجراتدم. سیکا حات یازوب
صالدم دیدی. امتحانلارنک اون بیشنچی سنتابرده باش
لانو احتماللری بار ایکان. سیکا امتحانلارده بولرغه
کیره ک کمی؟ قایچان قایتارغه اویلیسک. بزده سینی
بیله صاغنابز، لکن تیبی اوزک ایتودک حسابه
بیرگه یارامی، بو قدر مصرف لی یولغه کیتکاچ


استقاحقلی ده اولووی لازم .
کیچه توری زنیا یکینی کوردم . آلار بوگون کامیداه
قاتیلارغه اوینیلار ایکاره اینیزی . چونکه بوآی صوگننده
هاویه خانم سفرده ن قایتادی ده اول قامیقاه توشکه
اقدسن بله اوینه بولی غه تلی دی . آلارنگ کامیکده
باروب کوروگه بر تورلی وقت بولمادی . اقسف سنی بر
کورگانده ن بیرلی هیچ کورگانم یوق ، بلکه حاضر کامیده ن
قامیقاچ کورد .
ده سنینگ کوی اوتکاده حاتمه می یازارغه اونوتقانمن !
سویم اوچون ه بو دوااوغه ایکی شیشه
flüssige Kamillenseife آل .
اول صابوننگ توری ایسملی لری بولا . مین آلاتورد-
غانی فوومبا ایدی ، آنداه صولهٔ کامیللوز ایدیکانی
بار بوغای . قایسی بولساده یارار ، تیک تاچارلیقلی بو-
لماسون ، für blondes Haar دیب
آل . اویوقتی بوآی قیمتلی سوآلفانلق حیبی بولمس .
کادیقمیدهن میه تیتیش ده ن بر ایکی بار . بر آی آرزانلیه
سوزتی ده آل ، آلوب قایتا آلسانگ . آقچه بولماسا بیله
آلماسانگ ده یارار ، اوزنگ قارارسنگ ، تیکه سویم
اوچون بولغان صابنیی اونوتما ، اول بیک مهم .


باشقه یازاله دی جیرلر یوق ده بوغای آدتقا. نیچک ده
سینی قامتیقایمی اورنلاشوب قوتقان بولسام یاخشی بولا ایدی.
نیچک بولوب قالا اینری.
سینه‌لی ترداشلرینه آقچه یبه‌روونی اونتقانلر، مین
بر یولی یبه‌ررمن، باشقا یوللر اوچون بر سوز د. شونیه
آلمیم، زه‌ستیه بر له سویله‌شکنزم، مین اوزمده هر آی
شه‌تیلرمه یبه‌روب توردم دیدم. اوزی بلیب بر جواب
اویدر. آلار بو جیبه‌روم اوچون سیکا یگری بیرمارکا
آقچه بیررگه تیوشله ده آلودمنی.
شونی بر له بو گونگه تمام ایتم. اوی بوغا کیته دگد وقت
جیقب بارا. هر کون اوریده دورت بیش ساعت
بولنام. حسنه بیله کوب تورگل شول، آلای ده بر آلله بار.
چه‌چقلر مللکده اوسیورلر.

سینی بیله صاغنب سلاملشکنی تاب
سبیق،

شه‌مینه هانملرغه کوب سلام، شولایوق باشقا
بوتونده تانشنی بلکانه ده.
سین کییکلرنی بیله یالغز قالماماق اوچون بر آز تانشلرغه
سینیما لاردغه بارغالا، بوتون کون بیل اشقاغی آخشاملرغه یال
ایتوگه کیرک.

...RK TARİH KURUMU

Мәкаләдә күрсәтелгән әлеге хат татар мөһаҗирләренең көнкүреш тормышын, эшчәнлеген ачыкларга ярдәм итә, авторның хисләре турында мәгълүмат бирә. Рабига Аратның сөйгәненә ихтирамын, тулаем ышанычын, якты киләчәккә өметен чагылдыра. Татар хатын-кызының гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урынын күрсәтә, ватаныннан читтә яшәргә мәҗбүр булган ханымнарның тормышындагы һәм һөнәри эшчәнлекләрендәге авырлыкларны ачып сала. Рабига ханымның үз кулы белән язган әлеге хаты зыялы Арат гаиләсенең шәхси тормышының кайбер мизгелләре белән дә танышырга мөмкинлек бирә.

*КУШЫМТА*

**Хат**

Доктор Истанбул: 20.VIII.1935
Рабига Рәхмәти Арат
Диплом номеры: 753/3170
Чагалоглу, Нуруосманийе урамы, № 30
(Капалы фырын каршысында)
Тел: 21614

Рәшиткәем!

Кичә синең озын хатыңны алдым. Бу көннәрдә инде көтә идем. Исән хәбәреңне белеп бик шатландым. Сөем дә рәсемнәргә бик сөенде. Кичә аны беренче мәртәбә буларак монда яңа өйгә алып килгән идем. Бик яратты. Үзенә монда иптәшләр дә тапты. Шуның өчен без монда гына калыйк дигән була. Өй, җыештыргач, ярыйсы гына булды. Монда үзем генә булганга, эш күп булды. Бик акрын-акрын гына урнаштырдым әйберләрне. Инде эш бетте.

Минем урнашуыма килгәндә, әле мин һаман урнашканым юк. Минем сиңа сирәк язуымның сәбәбе дә шуның өчен. Менә урнашам, менә урнашам, урнашкач Рәшитне шатландырып язармын дип торып, вакыт үтә дә үтә. Нәшәт Өмәр[1] кайтты һәм менә бүгенгә күрешергә килергә кушкан иде. Бардым, деканнан хатны бирдем, укыды. «Сез төрек ватандашымы», ди, мин әйтәм «әйе», «фәкать сез кияүдә» ди. «Ярый, мин декан белән күрешим дә, сезгә җавап бирермен. Шимбә көн шалтыратыгыз», ди. Димәк тагын дүрт көннән. Тагын озын дүрт көнне билгесезлек эчендә үткәрергә кирәк.

Белсәң иде, Рәшиткәем, бу көтүдән, бөкләнүдән ни кадәр туйганымны. Кайвакыт докторлыгымнан бөтенләй ваз кичү дәрәҗәсенә җитәм. Сине мондый күңелсез нәрсә язып борчуыма гафу ит. Язмыйчы булмый. Тик бүген Нәшәт Өмәрдән тагын бик нервыланып кайттым. Димәк, бу юлы да, бәлки минем гаиләле булуымны сәбәп итеп алачаклар.

[1] Нәшәт Өмәр Ирдәлп (1882–1948) – табиб, Төркия Җөмһүриятенең беренче президенты Ататөрекнең табибы, профессор, Истанбул университеты ректоры (1927–1934).

Юкса вакыт күңелле генә үтә. Гөзтәпәдән Истанбулга килүдә юлда вакыт күңелле үтә. Танышлар күп. Кичә кайтканда декан Аллаһяр бәй белән танышып, сөйләшеп кайттым. Самими *(ихлас)* сөйләште.

Пароходка кергәндә Ниязины очраттым. Сиңа хат язып салдым диде. Имтиханнарның унбишенче сентябрьдә башлану ихтималлары бар икән. Сиңа имтиханнарда булырга кирәкме? Кайчан кайтырга уйлыйсың? Без дә сине бик сагынабыз, ләкин әлбәттә, үзең әйтмешли, хискә бирелергә ярамый, бу кадәр чыгымлы юлга киткәч, файдалы да булуы кирәк.

Кичә Нури Зыя бәйне күрдем. Алар бүген лагерьдан кайтырга уйлыйлар икән инде. Чөнки бу ай ахырында Һәдия ханым[2] сәфәрдән кайта ди. Ул кайткан төшкә Әкъдәс бәй[3] өйдә булырга тели ди. Аларның лагерьларын барып күрергә бер төрле вакыт булмады. Әкъдәсне бер күргәннән бирле һич күргәнем юк. Бәлки хәзер лагерьдан кайткач керер.

[...] Ничек тә син кайтканчы урнашып куйган булсам яхшы була иде. Ничек булып кала инде.

[...] Шуның белән бүгенгә тәмам итәм. Пароходка китәргә вакыт җитеп бара. Һәр көн өйдә дүрт-биш сәгать булам. Авырулар бик күп түгел әле, алай да бераз бар.

Балалар кулларыңнан үбәрләр.

Сине бик сагынып, сәламәтлек теләп, Рабигаң.

Әминә ханымнарга күп сәлам. Шулай ук башка бөтен таныш-белешләргә дә.

Син кичләрне бик ялгыз калмас өчен бераз танышларга, киноларга баргала. Көне буе эшләгәч, акшамларын *(кичләрен)* ял итәргә кирәк.

## КЫСКАРТЫЛМАЛАР

TTK – Türk Tarih Kurumu Arşivi (Төрек тарих җәмгыяте архивы)

## ЧЫГАНАКЛАР

TTK_Fi_2_6_6 (Türk Tarih Kurumu Arşivi (Төрек тарих җәмгыяте архивы)).

## ӘДӘБИЯТ

*Arslan R.* Doktor Rabia Arat'ın kısaca tercümei hali // Kazan. 1974. № 13. S. 41–42.

*Çağatay S.* Reşid Rahmeti Arat // Türk Tarih Kurumu Belleten. 1965. C. 29. S. 113. S. 177–193.

[2] Һәдия ханым – Әкъдәс Нигъмәт Куратның тормыш иптәше.

[3] Әкъдәс Нигъмәт Курат (1903–1971) – татар чыгышлы төрек тарихчысы, профессор.

**Автор турында белешмә:** Гайнанова Миләүшә Рамил кызы, тарих фәннәре кандидаты, диннәр тарихы һәм иҗтимагый фикер бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); mgaynanova@gmail.com

*Редакциягә керде 21.02.2023* *Кабул ителде 28.04.2023*

## РАБИГА АРАТ – «САМООТВЕРЖЕННЫЙ ДОКТОР С ТОНКОЙ ДУШОЙ»

***М.Р. Гайнанова***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*mgaynanova@gmail.com*

В статье анализируется письмо Рабиги Арат, адресованное супругу, известному ученому, тюркологу Рашиту Рахмати Арату. В представленном документе Рабига ханум пишет о семейных новостях, жизни татарского эмигрантского сообщества. Данный документ личного происхождения позволяет воссоздать картину жизни татарских эмигрантов за рубежом. Письмо Рабиги Арат содержит информацию о повседневной жизни, взаимоотношениях в семье и с друзьями. В нем приводятся сведения, показывающие место татарской женщины в социальной жизни Турции. Лейтмотивом текста служат переживания Рабиги ханум о своей профессиональной деятельности в эмиграции. Она получила высшее образование в европейской стране, но ее знания и профессиональный опыт в Турции не были востребованы. Рабига ханум, воспитанная в татаро-мусульманской среде, выбирает семейные ценности.

Цель статьи – показать результат анализа письма Рабиги Арат, в котором представлена ее повседневная жизнь в новой стране и ее отношение к окружающим проблемам, к разным событиям.

В работе приводится оригинал письма Рабиги ханум с переводом на современный татарский язык, где представлены личная жизнь женщины, ее переживания и душевные метания по поводу карьеры, взаимоотношения с татарскими деятелями и ее личное восприятие всего происходящего. Знакомство с архивным материалом позволяет раскрыть неизвестные факты о жизни семьи Рашита Рахмати Арата. Письмо впервые вводится в научный оборот.

**Ключевые слова:** Рабига Арат, Турция, частные архивы, эпистолярный жанр, биография.

**Для цитирования:** *Гайнанова М.Р.* «Фидакарь һәм нечкә күңелле табибә» Рабига Арат // Историческая этнология. 2024. Т. 9. № 1. С. 112–121. DOI: 10.22378/he.2024-9-1.112-121

**Сведения об авторе:** Гайнанова Миляуша Рамилевна, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела историй религий и общественной мысли, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); mgaynanova@gmail.com

*Поступила 21.02.2023 Принята к публикации 28.04.2023*

## RABIGA ARAT – "A DEDICATED DOCTOR WITH A SUBTLE SOUL"

***M.R. Gaynanova***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*mgaynanova@gmail.com*

The article analyses a letter by Rabiga Arat addressed to her husband, the famous scholar, Turkologist, Rashit Rahmati Arat. In the submitted document, Rabiga khanum writes about family news and the life of the Tatar emigrant community. This document of personal origin allows us to recreate a picture of the life of Tatar emigrants abroad. Rabiga Arat's letter contains information about daily life, relationships in the family and with friends. Information is also provided showing the place of the Tatar woman in the social life of Turkey. The leitmotif of the text is Rabiga khanum's experiences about her professional activities in exile. Having received higher education in a European country, her knowledge and professional experience in Turkey were not in demand. Brought up in a Tatar-Muslim environment, Rabiga khanum chooses family values.

The purpose of the article is to show the result of the analysis of Rabiga Arat's letter, which describes her daily life in the new country and her attitude to current problems and various events.

The work presents the original letter of Rabiga khanum with a translation into the modern Tatar language, which presents the woman's personal life, experiences and mental wanderings about her career, relationships with Tatar figures and her personal perception of everything that happens. Encounter with this archive material allows to reveal unknown facts about the life of Rashit Rahmati Arat's family. The letter is being introduced into scientific circulation for the first time.

**Keywords:** Rabiga Arat, Turkey, private archives, epistolary genre, biography.

**For citation:** Gaynanova M.R. (2024) Rabiga Arat – "a dedicated doctor with a subtle soul". *Istoricheskaya etnologiya* [Historical Ethnology]. Vol. 9. No. 1: 112–121. DOI: 10.22378/he.2024-9-1.112-121 (In Tat.)

REFERENCES

Arslan R. (1974) A brief biography of Dr. Rabiga Arat. *Kazan* [Kazan]. No. 13: 41–42. (In Turk.)

Çağatay S. (1965) Rashid Rahmeti Arat. *Türk Tarih Kurumu Belleten* [Bulletin of the Turkish Historical Society]. Series 29. No. 113: 177–193. (In Turk.)

**About the author:** Milyausha R. Gaynanova is a Cand. Sc. (History), Senior Research Fellow at the Department of the History of Religions and Public Thought, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); mgaynanova@gmail.com

*Received February 21, 2023 Accepted for publication April 28, 2023*